


Һәр миллəтнен vз бәйрәмнәре бар. Моселман календаре буенча татар халкынын дини бәйрәмнәреннән ин зурлары- Ураза гаете һәм Корбан бәйрәм. 25 нче июньдә ислам доньясында ин олуг бәйрәмебез - Ураза бәйрәмен каршыладык.  Ә инде икенче июльдә Ломат авылында Рамазан аенын тәмамлануына багышланган  авыл бәйрәме узды.
Бу чараны авылыбызнын  имамы Мусин Раиль Ряхим улы һәм культура эшчеләре оештырды. Мәжлескә районнан һәм республикадан кунаклар жыелды.      Кадерле кунагыбыз, безнен якташыбыз, Мордовия татарларынын «Якташлар» милли-мәдәни жәмгыяви автономия житәкчесе, Мордовия  Госсобрание социаль сәясәт комитеты председателе Рафаиль Зәкиевич Аширов барыбызны да бәйрәм белән котлады һәм бик кvп жылы сvзләр әйтте. «Кадерле дуслар, сезгә чын кvнелдән игелек, тынычлык һәм иминлек телим! Безгә торле милләтләр һәм диннәр арасындагы бабаларыбыз васыять итеп калдырган дуслыкны сакларга, тынычлыкны һәм татулыкны ныгытырга кирәк. Киләчәк коннәргә ышаныч белән карыйк, газиз Мордовиябыз, Ломатыбыз хакына, vзебезгә хас тырышлык белән, жаваплык тоеп эшлик», - диде ул.
Районыбызнын башлыгы Плешаков Сергей Геннадьевич жыелган халыкны бәйрәм белән котлады. Ломат авылынын югалып калмавын һәм горләп алга баруын теләде.



Раиль Рәхим улы Мусин барчабызга да изге теләкләр теләде. Рәхмәт кәгазләре һәм бvләкләр белән хормәтле кунакларны - Р.З.Аշировны, С.Г.Плешаковны, Н.В.Карасевны һәм актив мәдәният эшчеләрен котлады. Бар кочләрен мәдәният хезмәтенә багышлаган Ломат авылыбыз хезмәткәрләре Гелдvсә Шакир кызы Шабанова белән Венера Фәрит кызы Яхеева бvләкләнделәр. “Әлеге якты һәм изге бәйрәм – безнен борынгы

бабаларыбызнын бай рухи мирасынын аерылгысыз олеше. Без – моселманнарга, һәрвакыт диннәргә тигез карап, кvршеләр белән дустанә яшәv хас. Бу кvп гасырлар аша килгән кыйммәтләр – безнен горурлыгыбыз һәм уртак байлыгыбыз. Аларны без сакларга һәм vсеп килvче буынга тапшырырга тиешбез”, - диде ул.
Чыгыш ясаучылар кvп булды. Алар арасында эшмәкәребез Раимов Ринат Рафик улы. Ул, vзенен туып vскән Ломат авылы белән горурланып,  жәмәгатькә аяз кvк йозе, ак бәхетләр, корычтай нык сәламәтлек, кояштай озын гомер, чиксез шатлыклар теләде.
Бу конне торле-торле конкурслар булды: корәш, штанга кvтәрv, футбол матчы Кочкурово һәм Ломат командалары арасында һәм башка милли уеннар уйналды. Корәштә жинvчеләребезнен берсе булган Алмаевны атап китәргә булдым. Футболда Кочкурово спорт-сменнары беренче булса да, командаларында татар милләтле якташларыбыз байтак. Жинvнен олеше безгә дә тия дияргә момкин. Балалар очен батутлар оештырылган иде. Рәхәтләнделәр дә инде алар!
Бәйрәм булгач, сые да бар кунакчыл татарларыбызда. Барчабыз да тәмле плов, кайнар чәй, торле ризыклар белән сыйландык.
Читтә яшәгән авыл кешеләре дә, бу конне туган якларына кайтып, жан-нарына тынычлык таптылар. Бәй-рәмнән халык кvтәренке кәеф һәм оештыручыларга рәхмәт хисе белән таралышты.

**Альфия Узбякова**